Personalia

# THE FAMOUS SCIENTIST OF THE TURKIC WORLD

**Mirfatyykh Zakievich Zakiev,**
Tatarstan Academy of Sciences,
20 Bauman str., Kazan, 420111, Russia,
m.z.zakiev@mail.ru.



**ZAINULLIN MARAT VALEEVICH** (1935) is a Bashkir linguist, Doctor of Philology (1988), Professor and Member of the Bashkir Academy of Sciences, the Sector of Humanities (2005).

After graduating from the Teacher Training College (1954) he was enrolled at the Historical-Philological Department of Bashkir State University, where later he took a postgraduate course, and since 1962 he began teaching at BSU. In 1963, he defended his thesis on the category of the tense of the predicate

**ЗӘЙНУЛЛИН МАРАТ ВӘЛИ улы** (1935) − башкорт теле белгече, филология фәннәре докторы (1988), профессор, Башкортостан ФАнең гуманитар фәннәр академигы (2005).

Педагогия училищесын тәмамлагач (1954), Башкорт дәүләт университетының тарих-филология факультетында, аннан соң аспирантурада укый, 1962дән БДУда укыта башлый. 1963 елда фигыльнең заман категорияләре буенча кандидатлык диссертациясен,

**ЗАЙНУЛЛИН МАРАТ ВАЛЕЕВИЧ** (1935) − башкирский языковед, доктор филологических наук (1988), профессор, академик гуманитарных наук Башкирской АН (2005).

После окончания педагогического училища (1954) учился на историко-филологическом факультете Башкирского государственного университета, затем в аспирантуре, с 1962 года преподает в БГУ. В 1963 году защитил кандидатскую диссертацию по категориям времени сказуемого, в

and in 1988, he successfully defended his doctoral thesis “The functional-semantic category of modality in the modern Bashkir language”. For many years he worked as the dean of the Department of Philology of Bashkir State University. In 1990, he became the Head of the Chair of Bashkir Language and General Linguistics and in 1995, he was appointed the Chairman of the University Doctoral Council. Marat V.Zainullin supervised three doctoral and 20 candidate dissertations.

The focus of his research is grammar of the Bashkir language.

1988 елда «Хәзерге башкорт телендә модальлек функциональ-семантик категориясе» темасына докторлык диссертациясен яклый. Күп еллар БДУның филология факультеты деканы булып эшли, 1990 елдан башкорт һәм гомуми тел гыйлеме кафедрасы мөдире, 1995тән докторлык советы рәисе. Өч фән докторын, 20гә якын фән кандидатын әзерләгән.

Гыйльми хезмәтләре башкорт теле грамматикасына карый.

1988 году докторскую диссертацию на тему «Функционально-семантическая категория модальности в современном башкирском языке». Многие годы являлся деканом филологического факультета БГУ, с 1990 года – заведующий кафедрой башкирского языка и общего языкознания, с 1995 года – председатель докторского совета. Подготовил трех докторов наук, около 20 кандидатов наук.

Научные труды посвящены грамматике башкирского языка.

Every nation has great people who are its pride. Among the Bashkirs it is the greatest scholar and member of the Academy of Sciences Marat Valievich Zainullin. This year we celebrate his 80’s anniversary.

I have known Marat Valievich for a long time. As an associate professor of Kazan State University, I received an invitation to a scientific conference devoted to the grammar studies of the Turkic languages. This was an all-Union conference and it was held in August, 1957, in Ufa. There, Sufiyan Amirov, Harun Yusupov and I presented our speeches to the audience.

Jalil Kiekbaev, the chairman of the Chair of the Bashkir language in Bashkir Pedagogical Institute, held discussions on the development of the Turkic linguistics, encouraging young researchers from different Turkic language republics to actively participate in its work. The issue of young scientists and their involvement in an ongoing research was raised at the meeting, and the participants exchanged views on specific ways of engaging progressive-minded students in postgraduate studies.

The same year, the Bashkir Pedagogical Institute became State University and Jalil Iekbaev, as the Vice-Rector for Education, invited me to Ufa to deliver lectures to the students of the Tatar Philology faculty with participation of the Bashkir students.

I also supervised the students’ research, discussed its results, consulted on studies in the field of the Bashkir and Tatar languages and taught Academic writing. Among these students, there were two Marats and one of them had the surname of Zaynullin, I remembered him best of all.

Marat Valievich was born into a family of a teacher in Urge Saz village of the Kugarchino district in Bashkortostan[1] on November 5, 1953.On leaving the seven-grade school in his village, he entered Morak Teacher Training College, one of the famous institutions, which was 40 km away from the village. This college was a well-known center for education and culture.

Students studied humanitarian subjects such as the Russian language and literature, the Bashkir language and literature, and history. Marat Valievich left the school with honours, and in 1954, he entered the Bashkir State Pedagogical Institute (since 1957 it has been University), the Department of History and Philology. In the college, Marat was one of the best students and Jalil Kiekbaev guided his education for several years, preparing him for a postgraduate course.

Marat Zainullin did a postgraduate course and wrote his PhD thesis on the past verb tense and its meaning in the Bashkir and Tatar languages, following the advice of Jalil Kiekbaev. His great help and experience enabled Marat Zainullin to complete his outstanding PhD thesis. In 1963, I participated in the sitting of Kazan University Academic Council where Marat Zainullin presented his PhD thesis. Ever since, our creative friendship has been reflected in academic research, publications in scientific collections and this has been going on for 50 years.

As is known, in 1970s, Bashkir linguists compiled the academic grammar of the Bashkir language under the supervision of Yuldashev Ahnaf Ahmetovich, Doctor of Philology. This academic work was completed under the guidance of the Institute of History, Language and Literature of the Bashkir Science Academy of the USSR. In 1981,

[1] We used the information from the article *Great scientist, noble teacher and person* by Z.Uraksin

*Grammar of the Modern Bashkir Literary Language* (491 pages) was published by the Moscow publishing house "Nauka".

In this book Zainullin Marat Valievich was responsible for the sections titled *Modal Verb Forms*, *The Category of Mood*, *Indicative Mood*, *Participle*. He wrote about different patterns of modal forms and described their semantics [1]. In the unit on "Voice Category" he explores specific verb meanings.

In line with his research Marat Zainullin published two monographs, a manual, and dozens of articles. In 1988, he presented a doctorate thesis on the topic of his research, and it was highly appreciated. While writing a three-volume academic grammar of the Tatar language in 1991-1992, I made several speeches at the Institute of History, Language and Literature of the Bashkir Science Academy, at the Philology Faculty of Bashkir State University, and I always got a warm welcome from the Bashkir scientists, who also did research in this area and, eventually, published a book in 2002.

*Modern Bashkir Language*, written by N.Kh.Ishbulatov and M.Kh.Akhtyamov, is similar to *Tatar Grammar* and Pr. M.V.Zainullin was the editor of *Modern Bashkir Language*. Pr. Ishbulatov (Adverb), R.F.Zaripov, PhD in Philology (Noun Case Category) and Kh.V.Sultanbaeva, Associate Professor, (Postposition, Conjunction) took part in compiling the book *Modern Bashkir Literary Language. Morphology*. (386p.). However, the majority of the parts in this book were written by M.V.Zaynullin. This work can set an example for scholars compiling other Turkic grammar books. It includes results of recent research as well as new points of view expressed by Russian and Western linguistics [3]. For example, the unit about the category of mood covers such types of mood in Bashkir as 1) predicative, 2) narrative, 3) conditional, 4) of desire, 5) of purpose, 6) of possibility.

M.Zainullin repeatedly studied the indicative mood. It was the subject-matter of his PhD thesis, of his manual for students which includes extensive educational material and many examples. Owing to the original system, used to describe the language, his manuals have been used as textbooks for students for a long time.

Marat Valeevich Zainullin was held in high esteem for promoting academic research and organizing educational process at the University. Moreover, he was also good at delivering lectures and teaching students. For a long time he worked as the dean of the Faculty of Philology at Bashkir University. Under his guidance the Faculty developed new educational areas, for example "Bashkir and Foreign languages", the area suggested by Bashkir intelligentsia in the 1970s. Today, the faculty has such departments as "Bashkir and English", "Bashkir and German", "Bashkir and Arabian", "Bashkir and Russian" and "Bashkir and Turkish". It seems amazing: Bashkir young people from village schools are able to speak these languages and present their diplomas in English, German, Arabian and Russian. To develop these educational areas, the dean put a lot of effort into preparation of well-qualified teachers.

Since 1962 Pr. M.V.Zaynullin has been reading lectures and conducting seminars on "Introduction to Linguistics", "General Linguistics", "The Morphology of the Bashkir Language", and all this time he has continued to write books and methodological manuals.

Since 1990, M.V.Zaynullin has been the head of the Chair of Bashkir and General Linguistics. His students, with profound scientific interests, completed their post-graduate courses, and got a degree of the Candidate of Science. Under his supervision three Doctors of Science, who are well-known in the Turkic world (D.T.Tikeev, M.G.Usmanova and M.B.Ketenchiev), and about twenty Candidates of Science completed their theses.

Marat Valeevich scientific activity is especially appreciated for the preparation of highly-qualified staff for Bashkir, Tatar, Kazakh and other Turkic peoples as well as for non-Turkic nations. Since 1995, he has been theChairman of the Doctoral Council in the area of "Languages of Nations of the Russian Federation" and "Literatures of Nations of the Russian Federation".

Marat Zainullin taught highly qualified specialists not only for Bashkir, Tatar, and Kazakh nations but for other kindred Turkic peoples. Since 1995, he has been the Chairman of the Doctoral Council for doctoral theses on "Languages of the Peoples of the Russian Federation" and "Literature of the Peoples of the Russian Federation".

As the dean and head of the Department, Marat Valeevich organized different international, all-Russian and regional scientific conferences on the issues of the Bashkir and Turkic languages interactions, and submitted the results of his scientific research for publication. He put a lot of effort into the organization of conferences devoted to anniversaries of such outstanding scientists as N.K.Dmitriev, J.G.Kiekbaev, A.A.Yuldashev, K.Z.Akhmerov and his efforts were highly appre-

ciated. He keeps working actively on the implementation of the Law on the Bashkir language.

As recognition of Marat Zaynullin's contributions to the development of linguistic studies and preparation of highly qualified scholars, the Academy of Sciences of Bashkortostan first appointed him as a corresponding member in the Humanities (Linguistics) and, in 2005, he became an academician. Today, Marat Zaynullin continues his research into unsolved problems in linguistics.

**References**

1. Grammatika sovremennogo bashkirskogo literaturnogo yazyka. M.: Nauka, 1981. 495 s. (in Russian)
2. Tatarskaya grammatika. V 3 t. T.1. Vvedenie. Fonetika. Fonologiya/ Ros.AN, AN Tatarstana, In-t yaz., lit. i ist. im. G.Ibragimova. Kazan': Tatar. kn. izd-vo, 1993. 584 s.; Tatarskaya grammatika. V 3 t. T.2. Morfologiya/ Ros.AN, AN Tatarstana, In-t yaz., lit. i ist. im. G.Ibragimova. Kazan': Tatar.kn.izd-vo, 1993. 397 s.; Tatarskaya grammatika. V 3 t. T.3. Sintaksis/ Ros.AN, AN Tatarstana, In-t yaz., lit. i ist. im. G.Ibragimova. Kazan'': Tatar. kn. izd-vo, 1995. 576 s. (in Tatar)
3. *Zaynullin M.V.* Sovremennyy bashkirskiy literaturnyy yazyk. Morfologiya (na bashk. yaz.). Ufa: Kitap, 2005. 264 s. (in Russian)

---

# ТӨРКИ ДӨНЬЯДА ТАНЫЛГАН ГАЛИМ

**Мирфатыйх Зәки улы Зәкиев,**
Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе,
Россия, 420111, Казан ш., Бауман ур., 20 нче йорт,
m.z.zakiev@mail.ru.

Һәр халыкның мактанырлык һәм горурланырлык бөек, олы затлары була. Башкорт халкының андый шәхесләреннән мин зур галим, академик Марат Вәли улы Зәйнуллинны күрсәтер идем. Быел без аның 80 яшен тантаналы шартларда бәйрәм итәбез.

Марат Вәли улы белән танышуым бик күптән булды. Мин – Казан дәүләт университеты доценты – 1957 елның августында Уфада үткәреләчәк төрки телләрнең грамматик системасын өйрәнүгә багышланган гомумсоюз күләмендәге фәнни конференциягә чакыру алдым. Казаннан Суфиян Әмиров, Һарун Юсуповлар белән бергәләп, конференциядә чыгыш ясадым.

Башкорт педагогия институтынның башкорт теле кафедрасы мөдире Җәлил Киекбаев, төрки телле республикалардан килгән яшь галимнәрне үз янына чакырып, төрки телләр лингвистикасын үстерү турында әңгәмә үткәрде. Очрашуда яшь галимнәр әзерләү мәсьәләсе куелу сәбәпле, ул алдынгы студентларны аспирантурага тартуның конкрет юллары турында фикер алышты.

Шул ук елны Башкорт педагогия институты дәүләт университеты буларак эшли башлады. Җәлил ага Киекбаев – вузның уку-укыту эшләре буенча проректоры – мине, татар филологиясе бүлеге студентларына лекция уку өчен, Уфага чакырып алды. Лекцияләремнең кайберләренә Җәлил ага башкорт филологиясе бүлеге студентларын да алып керә иде.

Кичләрен гыйльми эш белән кызыксынучы студентлар оештырган фәнни түгәрәкләрдә мин дә катнаштым: студентларның фәнни эшләре нәтиҗәләрен тыңларга, башкорт яки татар телләреннән тикшеренү эшләре башкарган студентларга киңәшләр бирергә, фәнни эш язуның алымнарын өйрәтергә туры килде. Алар арасында ике Марат булып, берсе – Зәйнуллин дигәне – хәтердә ныграк сакланган.

Марат Вәли улы Башкортостанның Күгәрчен районында урнашкан, урамыннан чишмәләр агып яткан Үрге саз авылында укытучы гаиләсендә 1953 елның 5 ноябрендә дөньяга килә[1]. Шушы авылда җиде еллык мәктәпне тәмамлагач, заманында тирә-якта дан тоткан үз авылыннан 40 чакрым ераклыкта урнашкан Морак педагогия училищесена укырга керә. Бу уку йортын чын мәгънәсендә мәгърифәт һәм мәдәният үзәге дип йөртәләр.

Училищеда балалар рус теле һәм әдәбияты, башкорт теле һәм әдәбияты, тарих кебек гуманитар фәннәрдән төпле белем алалар. Марат Вәли улы училищены бик яхшы билгеләренә генә тәмамлап, 1954 елда Башкорт дәүләт педагогия институтының (1957 елдан –

[1] Биредә З.Ураксинның «Олы галим, абруйлы укытучы һәм шәхес» дигән мәкаләсеннән өзекләр кулланылды.

университетның) тарих-филология факультетына укырга керә. Марат югары уку йортында алдынгы студентлардан санала, Җәлил Киекбаев аны еллар дәвамында күзәтеп килеп, аспирантурага әзерли.

Ул аспирантурага кереп, диссертация язган чорларда, башкорт һәм татар телләрендә фигыльнең үткән заман формаларын һәм аларның мәгънәләрен кандидатлык диссертациямдә җентекләп тикшергәнлектән, Җәлил ага белән һәрчак киңәшеп торырга туры килде. Бу тәҗрибә гыйльми остазы аркылы Марат Зәйнуллин диссертациясенә дә йогынты ясагандыр дип беләм. 1963 елда Казан университеты диссертациясе Советында аның кандидатлык диссертациясен яклауда катнаштым. Шулай итеп, Марат Зәйнуллин белән ике арадагы иҗади дуслык, фәнни эштә, фәнни хезмәтләрне төрле җыентыкларда бастыруда бер-беребезгә ярдәм итешүебез 50 елдан артык дәвам итә.

Мәгълүм булганча, XX гасырның 70 елларында башкорт лингвистлары филология фәннәре докторы Әхнәф Әхмәт улы Юлдашев җитәкчелегендә башкорт теленең академик грамматикасын төзиләр. Бу академик хезмәт СССР Фәннәр академиясе Башкорт филиалы Тарих, тел һәм әдәбият институты планы буенча башкарыла. 1981 елда 495 битлек «Грамматика современного башкирского литературного языка» китабы Мәскәүнең «Наука» нәшриятында басылып та чыга. Аның «Формы модальности глагола (Фигыльнең модальлек формалары)», «Категория наклонения (Наклонение категориясе)», «Изъявительное наклонение (Хикәяләү наклонениесе)», «Причастие (Сыйфат фигыль)» дигән бүлекләрен Марат Вәли улы Зәйнуллин яза. Мәсәлән, «Формы модальности (Модальлек формалары)» дигән бүлектә галим модаль формаларның төрле конструкцияләрен аерып карый һәм аларның мәгънәләрен ачып бирә [1].

«Юнәлеш категориясе» бүлегендә фигыльнең конкрет мәгънәләре җентекле тикшерелә. Модальлек категориясен ныклап өйрәнеп, Марат Вәли улы ике монография, бер уку кулланмасы, дистәләгән мәкаләләр бастырып чыгара. 1988 елда ул бу темага докторлык диссертациясен яклый. Хезмәтенә һәрьяклап югары бәя ала.

1991-1992 елларда русча язылган татар теленең өч томлык академик грамматикасын төзегән елларда миңа эш барышы турында Башкортостандагы Тарих, тел һәм әдәбият институтында, Башкорт дәүләт университетының филология факультетында галимнәр алдында берничә мәртәбә чыгыш ясарга туры килде һәм алар җылы кабул итте [2]. Башкорт галимнәре үзләре дә бу юнәлештә актив эшләп, 2002 елда ике китап итеп бастырып чыгардылар.

Н.Х.Ишбулатов, М.Х.Әхтәмов авторлыгындагы «Хәзерге башкорт теле» хезмәте эчтәлеге белән «Татар грамматикасы» китабының беренче томына якын һәм аның җаваплы редакторы – филология фәннәре докторы, профессор М.В.Зәйнуллин.

«Хәзерге башкорт әдәби теле. Морфология» (386 б.) китабын язуда профессор Н.Х.Ишбулатов («Рәүеш»), филология фәннәре кандидаты Р.Ф.Зарипов («Исемнәрзең килеш категорияһы»), доцент Х.В.Солтанбаева («Бәйләүсе», «Теркәүес») да катнаша. Әмма күпчелек бүлекләр М.В.Зәйнуллин тарафыннан язылган. Башка төрки грамматистларына да үрнәк булырлык хезмәт рус һәм көнбатыш лингвистикасында ирешелгән соңгы елгы яңа казанышларны, ачышларны, яңа карашларны исәпкә алып язылган [3]. Мәсәлән, наклонение (һөйкәлеш) категориясе яктыртылган бүлектә галим башкорт телендә 1) хәбәр, 2) бойорок, 3) теләк, 4) шарт, 5) ният-максат, 6) фараз итү (ихтималлык) наклонениеләрен күрсәтә.

Хәбәр (татар телендә хикәя, русча изъявительное) наклонениесендә автор заман категориясе буенча үзенең кандидатлык диссертациясендә, күп мисалларны анализлау юлы белән төзегән, университет студентларына дистә еллар буе укыган гамәли дәресләрендә сыналган оригинал системасын бирә һәм ул телнең үз системасына туры килә. Аның әлеге хезмәтләре башка төрки халыкларда фигыльләрнең заман системасын тикшерү юнәлешендә үрнәк була ала.

Марат Вәли улы Зәйнуллин университетта фәнни эшләрне, уку-укыту, процессын системалы итеп оештыручы да, оста лектор да, игътибарлы тәрбияче дә. Озак еллар ул Башкорт универститетының филология факультеты деканы булып хезмәт итте. Ул җитәкләгән чорда факультет тагын да үсеп-киңәеп, анда яңа юнәлешләр, мәсәлән, башкорт зыялылары XX гасырның 70 елларында ук зарурлыгын күтәреп чыккан «Башкорт теле һәм чит телләр» бүлеге ачылды. Хәзерге көндә факультетта «башкорт һәм инглиз теле», «башкорт һәм немец теле», «башкорт һәм гарәп теле», «башкорт һәм рус теле», «башкорт һәм

төрек теле» белгечлекләреннән белем бирү тормышка ашырыла. Гаҗәеп хәл: кичә генә авыл мәктәбен тәмамлаган башкорт яшьләре инглиз, немец, гарәп, рус телләрендә диплом эшләре язып, аларны яклап та чыгалар. Ә бу юнәлешләрне тиешле югарылыкта алып бару өчен, деканга махсус кафедралар оештырырга, югары квалификацияле укытучылар әзерләргә кирәк була.

Профессор М.В.Зәйнуллин 1962 елдан бирле университетта «Тел гыйлеменә кереш», «Гомуми тел гыйлеме», «Башкорт теленең морфологиясе» курсларыннан лекцияләр укый, гамәли дәресләр алып бара һәм шул ук фәннәрдән китаплар, методик әсбаплар-кулланмалар төзеп бастырып чыгара.

1990 елдан башлап, М.В.Зәйнуллин башкорт һәм гомуми тел гыйлеме кафедрасы мөдире вазифасын башкара. Ул укыткан һәм гыйльми хезмәткә кызыксынку уяткан студентлар аспирантурада калып, фән кандидаты дәрәҗәсен алалар Аның җитәкчелегендә төрки дөньяда танылган өч фән докторы (Д.С.Тикеев, М.Г.Усманова, М.Б.Кетенчиев), егермегә якын фәннәр кандидаты әзерләнде.

Башкорт, татар, казах һәм башка төрки, шулай ук төрки булмаган күрше халыкларга югары квалификацияле кадрлар әзерләүдә дә Марат Вәли улының хезмәте югары бәягә лаек. 1995 елдан бирле ул БДУ каршында диссертантларга «Рәсәй Федерациясе халыклары телләре» һәм «Рәсәй Федерациясе халыклары әдәбиятлары» юнәлешендә фәнни дәрәҗә бирү вәкаләтенә ия булган докторлык советын җитәкли.

Кафедра мөдире һәм декан буларак, Марат Вәли улы башкорт теле, төрки телләрнең үзара мөнәсәбәтләре, төрки һәм рус теле бәйләнешләре һәм башка актуаль проблемалар буенча халыкара, гомумрәсәй, региональ фәнни конференцияләр оештырып, аларның материалларын тупланган гыйльми җыентыкларны әзерләп чыгарды. Шул ук вакытта башкорт телен өйрәнүгә зур өлеш керткән Н.К.Дмитриев, Дж.Г.Киекбаев, Ә.Ә.Юлдашев, К.З.Әхмәров кебек галимнәрнең юбилейларына багышланган конференцияләрне дә югары дәрәҗәдә оештыруга зур көч куйды. Ул Башкортостандагы телләр законын гамәлгә кую юнәлешендә дә актив эш алып бара.

Марат Вәли улы Зәйнуллинның тел гыйлеме өлкәсендәге хезмәтләрен фәнни эшләрне оештыру һәм аның югары квалификацияле кадрлар әзерләүдәге эшчәнлеген югары бәяләп, Башкортостан Фәннәр академиясе 2002 елның апрелендә аны гуманитар фәннәр (тел гыйлеме) буенча мөхбир-әгъза итеп сайлады. Фәнни тикшеренү, фәнни эшләрне оештыру, югары квалификацияле кадрлар әзерләүдә армый-талмый хезмәт итүен истә тотып, Башкортостан Республикасы Фәннәр академиясе 2005 елда аңа академик дәрәҗәсен бирде. Хәзерге вакытта ул әлеге мөһим юнәлешләрдәге эшчәнлеген академик буларак югары дәрәҗәдә алып баруны дәвам итә.

**Әдәбият**

1. Грамматика современного башкирского литературного языка. М.: Наука, 1981. 495 с.
2. Татарская грамматика. В 3 т. Т.1. Введение. Фонетика. Фонология / Рос.АН, АН Татарстана, Ин-т яз., лит. и ист. им. Г.Ибрагимова. Казань: Татар.кн.изд-во, 1993. 584 с.; Татарская грамматика. В 3 т. Т.2. Морфология / Рос.АН, АН Татарстана, Ин-т яз., лит. и ист. им. Г.Ибрагимова. Казань: Татар.кн.изд-во, 1993. 397 с.; Татарская грамматика. В 3 т. Т.3. Синтаксис / Рос.АН, АН Татарстана, Ин-т яз., лит. и ист. им. Г.Ибрагимова. Казань: Татар.кн.изд-во, 1995. 576 с.
3. *Зайнуллин М.В.* Современный башкирский литературный язык. Морфология (на башк. яз.). Уфа: Китап, 2005. 264 с.